| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.11.2024 Казан ш № 775

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына караган ведомство казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясының 4 пунктын гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч түләвенә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына караган ведомство казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен (кушымтада) расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Э.Н.Нигъмәтҗановага йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2024 елның 19 ноябрендәге 775 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына караган ведомство казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) һәм Министрлыкка буйсынучы казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү кагыйдәләрен һәм шартларын билгели.

Министрлык боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетының башка керемнәре администраторларының (алга таба – бюджет керемнәре администраторлары) бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Министрлыкка буйсынучы казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү әлеге Тәртип нигезендә мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырыла.

Бюджет керемнәре администраторы булмаган Министрлык буйсынуындагы казна учреждениесенең бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турындагы карары әлеге Тәртип нигезендә Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Министрлык (бюджет керемнәре администраторлары) тарафыннан карар кабул итү өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

а) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче – физик затның үлеме яки аны Россия Федерациясенең гражданлык процессуаль законнары нигезендә үлгән дип игълан итү;

б) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гражданинның, шәхси эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау – күрсәтелгән Федераль закон нигезендә аларның түләү йөкләмәсен үтәүдән азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурычлар өлешендә;

в) оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле Татарстан Республикасы бюджетына түләнмәгән түләүләр буенча бурычы өлешендә оешма – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче зат бетерелгән очракта;

д) штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында актлар кулланылганда яки бюджет керемнәре администраторы

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча әҗәтләрне түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары кабул ителгәндә, шул исәптән аны түләттерүнең билгеләнгән срогы үтүгә бәйле рәвештә дә;

е) «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр бурыч барлыкка килгән көннән бурычлыга карата бөлгенлек турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаса, башкаручы суд приставы тарафыннан башкару эшен тәмамлау турында карар чыгару (бөлгенлек) банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен биш елдан артык вакыт узган булса;

ж) бюджетка түләүләр түләүче затны банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты кабул итү;

з) теркәүгә ала торган орган тарафыннан юридик зат Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРЮЛ) төшереп калдырылганда һәм, 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча үтәтү документын түләттерүче затка кайтарып, үтәтү эшчәнлеген туктату турында суд пристав-башкаручысы тарафыннан элегрәк чыгарылган карар булганда, – оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле Татарстан Республикасы бюджетына түләнмәгән түләүләр бурычы өлешендә. «Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә теркәүгә ала торган органның юридик затны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлдә түгел дип танылган очракта, әлеге пунктча нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча элегрәк түләттерү өчен өметсез дип танылган бурычы бюджет (бухгалтерия) исәбендә торгызылырга тиеш.

3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, түләнмәгән административ штрафлар, әгәр административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ җәза билгеләү турындагы карар үтәлешен туктату турында карар чыгарылган булса, түләттерү өчен өметсез дип танылa.

4. Министрлык (бюджет керемнәре администраторлары) әлеге Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән нигезләр буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итә, алар түбәндәгеләр белән расланырга тиеш:

а) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләрне түләү буенча бурычларның исәпкә алына торган суммалары турында бюджет керемнәре администраторы белешмәсе;

б) Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^1$ статьясы нигезендә билгеләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтүнең бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган түләүләр

буенча бурычларны түләтүне тәэмин итүдә күрелгән чаралар турында бюджет керемнәре администраторы Министрлык белешмәсе;

в) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану очракларынраслый торган документлар белән, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче физик затның вафат булуын таныклый торган яисә аны вафат булган дип игълан итү фактын раслый торган документ белән;

конкурс эшчәнлеген тәмамлау яисә шәхси эшкуар булып торган гражданин – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның мөлкәтен сатуны төгәлләү турында суд акты, шулай ук Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан үзен бөлгән (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә физик зат – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатуы турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ белән;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче гражданинның мөлкәте буенча конкурс эшен тәмамлау яисә сатуны төгәлләү турында суд акты белән;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшчәнлек туктатылуы турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр булган документ белән;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче юридик затны теркәү органы карары буенча күрсәтелгән реестрдан чыгару турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар булган документ белән;

штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында акт яки бюджет керемнәре администраторы Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд акты белән, шул исәптән аны түләттерүнең билгеләнгән чоры узуга бәйле рәвештә дә;

229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясының 1 елешендәге 3 яки 4 пунктында каралган нигезләр буенча производство эшчәнлегенең тәмамлануы һәм производство документларының түләттерүчегә кайтарып бирелүе сәбәпле суд приставы-башкаручысы карары белән;

бюджетка түләүләр түләүче затны бөлгән (банкрот) дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты белән;

административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турындагы карар белән;

гражданинның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында банкротлык турындагы белешмәләрнең Бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ белән.

5. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Министрлык (бюджет керемнәре администраторы) карарларын әзерләүне һәм кабул итүне Министрлык хезмәткәрләре (бюджет керемнәре администраторлары) арасыннан кимендә биш кешедән торган составта төзелә торган активлар керү һәм китү буенча даими эшләүче комиссия (алга таба – комиссия) гамәлгә ашыра.

6. Комиссия составы Министрлык (бюджет керемнәре администраторы) боерыгы белән раслана. Комиссия составына комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре, комиссия әгъзалары керә.

7. Комиссия эше аның утырышларында гамәлгә ашырыла, алар, әлеге Тәртипнең 2-4 пунктларында күрсәтелгән нигезләрнең һәм документларның берсе булганда, елына кимендә бер мәртәбә уздырыла.

8. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, комиссия үз функцияләрен башкарырга хокуклы.

9. Комиссия рәисе комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары яисә аның вазыйфаларын башкаручы зат башкара.

Комиссия секретаре комиссия утырышы беркетмәсен алып бара, комиссия утырышларын әзерли, комиссия утырышына кагылышлы барлык мәсьәләләр буенча комиссия әгъзаларына хәбәр итә, шул исәптән комиссия утырышларын үткәрү урыны, датасы һәм вакыты турында аларга вакытында хәбәр итә һәм комиссия әгъзаларын кирәкле материаллар һәм документлар белән тәэмин итә.

10. Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш биргәндә комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Тавышлар тигез булганда, комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Комиссия әгъзалары тарафыннан читтән торып тавыш бирү уздыру юлы белән карар кабул итү, шулай ук башка затларга үз вәкаләтләрен тапшыру рөхсәт ителми.

11. Комиссия Министрлыкның вәкаләтле затлары (бюджет керемнәре администраторы) тарафыннан әлеге Тәртипнең 2-4 пунктларына туры килү-килмәве турындагы документларны алар тапшырылган көннең иртәгесеннән биш эш көне узганчы карый һәм Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында яисә мондый карар кабул итү өчен нигезләрнең булмавы турында карар кабул итә.

12. Комиссия утырышы йомгаклары буенча әлеге Тәртипнең 11 пунктында каралган карарларның берсе кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә беркетмә рәсмиләштерелә, аңа комиссиянең утырышта катнашкан барлык әгъзалары имза сала.

Комиссия Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул иткән очракта, комиссия секретаре комиссия утырышы беркетмәсен рәсмиләштергән көннән алып ике эш көне узганчы Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар проектын (алга таба - карар проекты) республика бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Россия Финанс министрлыгының «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең бюджет исәбен, бухгалтерлык исәбен алып барганда кулланыла торган бухгалтерлык исәбе электрон документларының һәм аларны булдыру һәм куллану буенча методик күрсәтмәләрнең унификацияләнгән рәвешләрен раслау турында» 2021 елның 15 апрелендәге 61н номерлы боерыгы белән расланган 0510436 формасы буенча акт (алга таба – Акт) рәвешендә төзи.

Акт комиссия утырышы беркетмәсе рәсмиләштерелгән көннән алып ике эш көне узганчыга кадәр комиссия рәисе һәм комиссиянең утырышта булган барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

Акт комиссия тарафыннан имзаланган көннән алып биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (бюджет керемнәре администраторы җитәкчесе) тарафыннан раслана яисә комиссиягә кире кайтарыла.

13. Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (бюджет керемнәре администраторы җитәкчесе) Акт комиссиягә кире кайтарылган очракта, комиссия Министрлыкның вәкаләтле затлары (бюджет керемнәре администраторы) тапшырган документларны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (бюджет керемнәре администраторы) Актны кире кайтарган көннең иртәгесеннән биш эш көне узганчыга кадәр кабат карый һәм әлеге Тәртипнең 11 һәм 12 пунктларында каралган барлык башка гамәлләрне башкара, шул исәптән әлеге Тәртипнең 11 һәм 12 пунктларында билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына (бюджет керемнәре администраторы җитәкчесенә) раслау өчен Актны кабат тапшыра.

14. Бюджет керемнәре администраторы Акты бюджет керемнәре администраторы җитәкчесе тарафыннан расланган көннән алып ике эш көне эчендә Министрлыкка килештерү өчен җибәрелә.

Министрлыкның бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге бюджет керемнәре администраторыннан Акт кергән көннән алып биш эш көне узганчы аны карый, кирәк булганда, бюджет керемнәре администраторыннан әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган өстәмә мәгълүматны соратып ала. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган нигезләр булганда, Министрлыкның бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы яисә аның вазыйфаларын башкаручы зат актның бюджет керемнәре администраторыннан кергән көннән алып биш эш көне узганчыга кадәр аңа виза куя һәм Министрлыкның Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре администраторлары булып торучы Министрлыкка буйсынучы казна учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан расланган керемнәр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турындагы актларны килештерүгә вәкаләтле вазыйфаи затына (алга таба – вәкаләтле вазыйфаи зат) тапшыра.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, Министрлыкның бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы яисә аның вазыйфаларын башкаручы зат, Акт бюджет керемнәре администраторыннан кергән көннән алып биш эш көне узганчыга кадәр, бюджет керемнәре администраторына әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган нигезләрнең булмавы һәм (яисә) тапшырылган Актта җитешсезлекләр турында язма рәвештә хәбәр итә.

Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты югарыда күрсәтелгән тәртиптә кул куелган Акт кергән көннән алып өч эш көне узганчы аны килештерә яисә килештерүдән баш тарта. Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан килештерелгән Акт яисә Актны килештерүдән баш тарту турында хәбәр, тапшырылган Актта баш тарту сәбәпләрен яисә җитешсезлекләрен күрсәтеп, Акт Министрлыкка кергән көннән алып 10 эш көне узганчы, бюджет керемнәре администраторына җибәрелә.

15. Актта түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме);

б) салым түләүченең идентификацияләү номеры, төп дәүләт теркәвенә алу номеры, салым түләүченең оешмасын исәпкә алуның сәбәп коды (физик затның салым түләүчесенең идентификацияләү номеры) (булган очракта);

в) бурычны барлыкка китергән түләү турында белешмәләр;

г) аның буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен классификацияләү коды, аның исеме;

д) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч суммасы;

е) Татарстан Республикасы бюджетына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

ж) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул ителгән көн;

з) комиссия әгъзаларының имзалары.

16. Бюджет керемнәре администраторы булып тормаган Министрлык буйсынуындагы казна учреждениесе, әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда, әлеге Тәртипкә 1 нче һәм 2 нче кушымталарда китерелгән рәвешләр буенча Министрлыкка Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләү буенча бурычларның исәпкә алына торган суммалары турында белешмә һәм Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында белешмә, шулай ук шулай ук әлеге Тәртипнең 4 пунктындагы "в" пунктчасы нигезендә бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану очракларын раслый торган документларны тапшыра.

17. Министрлык тарафыннан, бюджет керемнәре администраторы булмаган Министрлыкка буйсынучы казна учреждениесе тарафыннан Министрлыкка әлеге Тәртипнең 16 пунктында каралган документларны (материалларны, белешмәләрне) тапшырган көннән алып 15 эш көне тәмамланганчы, бюджет керемнәре администраторы булмаган Министрлык буйсынуындагы казна учреждениесенең бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында яисә бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип танудан баш тарту турында карары кабул ителә, ул тиешле карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне узганчыга кадәр Министрлыкка караган, бюджет керемнәре администраторы булмаган ведомство казна учреждениесенә җибәрелә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына караган ведомство казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә 1 нче кушымта

форма

Белешмә

_____________________________________________________________

(*дәүләт казна учреждениесенең исеме*)

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләү буенча исәпкә алына торган суммалар турында__ __________ 20__ ел. № ___

| Т/с | Юридик затның исеме, ИНН, ОГРН, КПП, физик затның Ф.И.А.(соңгысы - булган очракта), ИНН | Түләүнең исеме | Түләү суммасы (сумнарда) | Татарстан Республикасы бюджетына түләү буенча бурыч барлыкка килү датасы | Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләү йөкләмәләрен билгели торган документның исеме, номеры һәм датасы | Бурыч исәпкә алына торган бюджет керемнәре классификациясе коды |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| БАРЛЫГЫ | | | x | x | x | x |

Җитәкче

__________________ ________________________

(*имза*) (*инициаллар, фамилия*)

Баш бухгалтер

____________________ ___________________________

*(имза) (инициаллар, фамилия)*

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына караган ведомство казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә 2 нче кушымта

форма

Кабул ителгән чаралар турында белешмә

______________________________________________

*(казна учреждениесе исеме)*

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча

«__» ________ 20__ ел. № ___

| т/с | Юридик затның тулы исеме; физик затның Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) | Юридик затның ИНН, ОГРН, КПП; физик затның ИНН | Татарстан Республи-касы бюджетына түләүләр түләү йөкләмәләр | Бюджетка түләү йөкләмәсен үтәүнең тәнәфесе, кичектерелүе яисә ваклап түләтелүе | Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган бюджет керемнәре | Бюджетка бурыч суммасы (сумнар-да) | Бюджетка түләү буенча йөкләмәләрне билгели торган документны үтәлү срогы чыгу датасы | Түләтү буенча күрелгән чаралар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ен билгеле торган документ-ның исеме, номеры һәм датасы | турында белешмәләр (документның исеме, номеры, датасы, тәнәфеснең, кичектерелүе-нең яисә ваклап түләтелүенең тәмамлану датасы) | классификациясе коды | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |
| БАРЛЫГЫ | | | | | | | x | x |

Җитәкче

________________ ____________________

*(имза)* *(инициаллар, фамилия)*

Баш бухгалтер

________________ ____________________

*(имза)* *(инициаллар, фамилия)*